СОВЕТ КУРАЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КУРАЛОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

12.01.2016 с. Куралово 6-40

«Югары Ослан муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының һәм Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлеге башкарма комитетының җир кишәрлекләре белән чикләнмәгән һәм авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре белән эш итү мәсьәләләре буенча үзара бәйләнеш турындагы килешүне раслау хакында» Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлеге Советының 2015 елның 28 августындагы 43-247 номерлы Карарын бетерү турында

«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә, Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлеге Уставына таянып,

Югары Ослан муниципаль районының
Куралово авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. «Югары Ослан муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының һәм Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлеге башкарма комитетының җир кишәрлекләре белән чикләнмәгән һәм авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре белән эш итү мәсьәләләре буенча үзара бәйләнеш турындагы килешүне раслау хакында» Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлеге Советының 2015 елның 28 августындагы 43-247 номерлы карарын юкка чыгарырга.
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль район Советына җибәрергә.
3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карар 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районының
Куралово авыл җирлеге башлыгы Л.И.Коткова